РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 17 » 03 2022 г. №186

2022 елга салым салынырга
тиеш булган гражданнарның
максималь кереме күләмен һәм
максималь мөлкәт бәясен билгеләү
турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Ютазы муниципаль районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының 2022 елның 1 кварталына уртача базар бәясен раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 02 мартындагы 129 номерлы карары нигезендә, гражданнар кеременең максималь күләмен исәпләү өчен, 2022 елга Ютазы районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен - 28 571 сум күләмендә расларга.

2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2022 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь бәясе күләмен расларга (1-нче кушымта).

3. Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасарына социаль файдаланудагы торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә куйганда 1 нче кушымтада күрсәтелгән керемнең максималь күләмен файдаланырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан»

дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе С.П. Самонина

Н.А. Әбилтарова
2-76-81

1 нче номерлы кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
17.03.2022 ел,
№186 Карарына

**2022 елга салым салынырга тиеш булган һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган максималь керем күләме һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме**

| Гаилә әгъзалары саны | Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясе | Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме |
|---|---|---|
| 1 | 514 278 | 13 799 |
| 2 | 1 028 556 | 13 799,4 |
| 3 | 1 542 834 | 13 799,6 |
| 4 | 2 057 112 | 13 799,6 |
| 5 | 2 571 390 | 13 799,6 |
| 6 | 3 085 668 | 13 799,6 |
| 7 | 3 599 946 | 13 799,6 |
| 8 | 4 114 224 | 13 799,6 |
| 9 | 4 628 502 | 13 799,6 |
| 10 | 5 142 780 | 13 799,6 |